Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Чытырчы авыл җирлегенең Чытырчы авылындагы
гражданнар җыены

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлеге составына керүче Чытырчы авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 27 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2021 елда Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлегенең Чытырчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча 2020 елның 27 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- чокырлы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китерү, салу, килешүләр буенча түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 227 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 138 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

**«**РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 138 катнашучысы тавыш бирде;

**«**КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлегенең Чытырчы авылындагы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. «2021 елда Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлегенең Чытырчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

- чокырлы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китерү, салу, килешүләр буенча түләү).

3. Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлегенең Чытырчы авылы территориясендә 2021 елда үзара салымны, Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлегенең Чытырчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә кертергә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- чокырлы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китерү, салу, килешүләр буенча түләү).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элеп чыгу юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Чытырчы авыл җирлеге
башлыгы _________________ М.В.Новиков